| СОВЕТ НУРЛАТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОРЛАТ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

| РЕШЕНИЕ<br>«16» апрель 2024ел | Норлат ав. | КАРАР<br>№ 157 |
|---|---|---|

Норлат авыл җирлеге башкарма комитетының җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Норлат авыл җирлеге Советы

карар итте:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Норлат авыл җирлеге башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитетына тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

Җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

гарантияләнгән җирләү хезмәтләре исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдим Норлат авыл җирлеге башкарма комитетына кабул ителгән очракта:

Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

бюджет законнары нигезендә әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатыннан Норлат авыл җирлеге Советының 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләргә һәм карарга тәкъдим итәргә

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый информация рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы информация сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Норлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М. Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Идел Аръягы»үзәге бинасы) рәсми рәвештә игълан итәргә.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Норлат авыл җирлеге советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы, социаль – икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшкуарлыкны үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Норлат авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.М.Саттаров